**Межрегиональные предметные олимпиады КФУ**
**профиль «Татарский язык»**
**Заключительный этап**
**ОТВЕТЫ**
**2025-2026 учебный год**

**10-11 классы**

**I. Искергән сүзләрнең хәзерге татар әдәби телендәге вариантларын языгыз./** Напишите современные варианты устаревших слов. **(*10 баллов)*** *За каждый правильный вариант по 2 балла.*

**Имла** **-** дөрес язу, орфография
**Ошбу** – бу, шушы
**Ярлык** – фәрман, указ, боерык
**Иҗтиһат** –тырышлык
**Берлән** - белән

**II. Татар халык шагыйре С. Хәкимнең *Бер тауда ун чишмә, Сереңне син чишмә*** **шигъри юллары күпләргә таныш. Әлеге өзектә кулланылган *чишмә* сүзендә нинди аерма бар? Тел белемендә бу күренеш ничек дип атала? Җавабыгызны дәлиләгез**. / Многим знакомы строки татарского народного поэта С. Хакима: “Бер тауда ун чишмә, Сереңне син чишмә”. Объясните смысловое различие слова *чишмә* в данном отрывке. Как называется данное лингвистическое явление? Обоснуйте свой ответ. **(*20 баллов).*** *За верное толкование каждого значения по 5 баллов; за определение термина – 5 б.; за примеры-доказательства -5 б.*)

Шигырьнең беренче юлындагы *чишмә* сүзе исем сүз төркеменә карый, җир астыннан бәреп чыга торган *су чыганагы; кизләү* мәгънәсен белдерә. Икенче очракта – *чиш-* фигыленең юклык формасында килүе. Бу – омонимия күренеше, әлеге ике сүз – омоформалар. Мәсәлән, бар- бар, салма- салма, кара-кара һ.б.

**III. Сүзләрнең тамырын языгыз.** / Запишите корни предложенных ниже слова. **(10 баллов).** *За каждый правильный вариант по 2 б.*

Безелдәвек – без-
Сырганак – сыр-
Кисемтә – кис-
Кадак –када-
Аңлаешсызлык – аң-

**IV. Сүзләрнең татарча тәрҗемәсен языгыз. / Переведите слова на татарский** язык. *За каждый правильный вариант по 1 баллу*). **(10 баллов)**.

*Государство - дәүләт*

*Животный мир – хайваннар дөньясы*
*Претензия– дәгъва*
*Парикмахерская – чәчтарашханә*
*Голубь- күгәрчен*
*Здоровье – сәламәтлек*
*Гордость– горурлык*
*Строитель – төзүче*
*Критика- тәнкыйть*
*Ясность – ачыклык, аңлаешлылык*

**V. *Орфография* һәм *орфоэпия* терминнарына билгеләмә бирегез /** Дайте определение терминам *орфография* и *орфоэпия* **(10 баллов).** *За каждый правильно данное определение по 5 баллов.*

Орфография – Тел белеменең дөрес язу кагыйдәләрен, орфографик принципларны өйрәнә торган тармагы. Ул *орфо-* – дөрес, *графо–* язу сүзләреннән ясалган термин.

Орфоэпия - тел белеменең үрнәк әйтелеш нормаларын өйрәнә торган тармагы. Орфоэпия әдәби әйтелеш нормаларын билгели. Дөрес әйтелешнең үзен дә *орфоэпия* термины белән атап йөртәләр.

**VI. Шигырне укыгыз һәм күп нокталар урынына тиешле хәрефләрне куегыз.** / Прочитайте стихотворение и вставьте пропущенные буквы вместо многоточий **(10 баллов).** *За каждый правильный ответ по 1 баллу*.

**Буран**

Тик кенә торганда капланды тома**н**га бар **һ**ава;
Кар оча, кар себерелә, кар кот**ы**рына һәм кар ява.
Кар бәрә йөзгә рә**х**имсез, күз ачып булмый карап;
Һәр кара нәрсә — бүре һәм **һ**әр маяк булды карак.
Карны җиңгән күк, төшә җиргә тон**ы**к ай яктысы;
Ай да куркы**н**ган шикелле: бер сары, бер ак төс**е**.
Көн буе яткан иде, үлгән җылан күк, юл тыныч;
Чыкты соң кайдан адашт**ы**ргыч буран — бу курк**ы**ныч? (*Г. Тукайдан*)

**VII. Җөмләләрне укыгыз. Һәр җөмләдә бер үк сүз төшеп калган, аны табыгыз һәм тиешле формада куеп языгыз. 2 һәм 4 нче җөмләдә тамырдаш сүзләр дә төшеп калган, аларны да тиешле формада куеп языгыз. /** Прочитайте предложения. В каждом предложении пропущено одно и то же слово. Во 2 и 4 предложениях пропущены и однокоренные слова. Впишите их в нужной грамматической форме. *За каждый правильный ответ по 2 балла.* **(10 баллов)**.

1) **Кул** туңганда ике кат бияләй киеп җибәрәсең. 2) Аннары ул **кулына** портфелен тотып, китапларын **култык** астына кыстырып, саубуллашып чыгып китте. 3) Синең өчен **кулга** каләм алдым, синең өчен аны сындырдым. 4) Бишәр, унар, йөзәр әсир тоткан бәкләр эшче **кулсыз** калды.

**VIII.** ***Яхшы сүзгә таш эри*** **мәкален сез ничек аңлыйсыз? Шушы мәкальдә әйтелгән фикергә үз мөнәсәбәтегезне 80 сүздән ким булмаган язмада белдерегез. Фикерегезне раслап, 2 дән ким булмаган дәлил китерегез./** Как вы понимаете пословицу *От доброго слова камень тает*? Опираясь на это **выражение,** напишите сочинение-рассуждение (не менее 80 слов). Выражая свое отношение приведите не менее 2 довода-примера *(***20 баллов***)*.

| № | **Сочинениене бәяләү критерийлары** | **Баллар** |
|---|---|---|
| ***I*** | ***Иншаның эчтәлеге*** | |
| | Язманың эчтәлеге темага туры килә. Эчтәлеге тулысынча ачылган. Икедән артык дәлил бирелгән. | 4 |
| | Язманың эчтәлеге, нигездә, темага туры килә. Эчтәлеге ачылган. 1-2 гомуми дәлил бар. | 3 |
| | Язманың эчтәлеге гомуми. 1 дәлил бар. | 2 |
| | Язманың эчтәлеген бирүдә җитди ялгышлар бар. 1 дәлил дә юк | 1 |
| | Язманың эчтәлеге ачылмаган<br>**яки**<br>мисал буларак дәлил язылмаган. | 0 |
| ***II*** | ***Иншаның тел ягы*** | |
| | **Язманың мәгънәви бөтенлеге, сөйләм бәйләнешлелеге, язу эзлеклелеге** | |
| | Эш мәгънәви бөтенлеге, сөйләм бәйләнешлелеге һәм язу эзлеклелеге белән характерлана:<br>– логик хаталар юк, язуда эзлеклелек бозылмаган;<br>– абзацларга бүленештә хаталар юк. | 2 |
| | Эш мәгънәви бөтенлеге, сөйләм бәйләнешлелеге һәм язу эзлеклелеге белән характерлана,<br>**ләкин**<br>1 логик хатасы бар,<br>**һәм/яки**<br>абзацларга бүленештә **1** урында хата бар. | 1 |
| | Язмада сөйләм үстерүгә омтылыш бар,<br>**ләкин**<br>логик хаталарның саны 1 дән артык,<br>**һәм/яки**<br>абзацларга бүленештә **2** урында хата бар. | 0 |
| | **Төгәллек һәм сөйләм матурлыгы** | |

| | | |
|---|---|---|
| | Язмада фикер төгәл, төрле грамматик формалар кулланылган. | 2 |
| | Язмада фикер төгәл,<br>**Ләкин** бер генә төрле сөйләм калыпларыннан файдаланылган,<br>**яки**<br>язмада төрле грамматик формалар кулланылган,<br>**ләкин** фикер төгәллеге бозылган. | 1 |
| | Сүз байлыгыннан тиешенчә файдалана алмаган, бер үк төрле җөмлә калыпларын гына кулланган. | 0 |
| ***III*** | ***Грамоталылык*** | |
| | **Орфографик нормаларның үтәлеше** | |
| | Орфографик хаталары юк (яки тупас булмаган 1 хатасы бар). | 3 |
| | Хатасы 2 дән артык түгел. | 2 |
| | 3-4 хата җибәрелгән | 1 |
| | Хаталарының саны 4 тән артык | 0 |
| | **Пунктуацион нормаларның үтәлеше** | |
| | Пунктуацион хаталары юк (яки тупас булмаган 1 хатасы бар). | 3 |
| | 1-3 хатасы бар. | 2 |
| | 4-5 хатасы бар. | 1 |
| | Хаталарының саны 5 тән артык | 0 |
| | **Тел нормаларының үтәлеше** | |
| | Грамматик хаталары юк | 2 |
| | 1–2 хатасы бар | 1 |
| | Хаталарының саны 2 дән артык | 0 |
| | **Сөйләм нормаларының үтәлеше** | |
| | Сөйләмгә кагылышлы 1 генә хатасы бар | 2 |
| | **2–3** хатасы бар | 1 |
| | Хаталарының саны **3** тән артык | 0 |
| | **Этикага кагылышлы нормаларның үтәлеше** | |
| | Этикага кагылышлы хаталары юк | 1 |
| | Хаталары бар (1 һәм 1дән күбрәк) | 0 |
| | **Язмада фактларны бирүдәге төгәллекнең үтәлеше** | |
| | Фактик хаталары юк. | 1 |
| | Фактик хаталары бар. | 0 |
| **Язма эш өчен максималь балл** | | **20** |